Татарстан республикасы Мөслим муниципаль районы
муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе
Тат.Шуран төп гомуми белем бирү мәктәбе

КАРАЛДЫ
Методик берләшмә җитәкчесе:
_________ Вилданова Л.Р.
Беркетмә №1,
"29" нчы август, 2019 нчы ел.

КИЛЕШЕНДЕ
Уку-укыту эшләре буенча директор
урынбасары: ___________ Шаймухаметова Р.И.
"29" нче август, 2019 нчы ел.

РАСЛЫЙМ.
Мәктәп директоры
_________ В.М.Шаева.
Боерык № 77
"2" 09 _______ 2019 нчы ел.

# "ТУГАН ТЕЛ (ТАТАР ТЕЛЕ)"ННӘН ЭШ ПРОГРАММАСЫ

| | |
|---|---|
| Белем бирү баскычы | Башлангыч белеем бирү |
| Сыйныф | 1-4 |
| Эш программасын үзләштерү арагыгы | 2019- 23 |
| Үзләштерү дәрәҗәсе (база, профиль) | база |
| Төзүчеләр | Вилданова Ләйсән Рәсим кызы, I квалификацион категорияле укытучы<br>Нурлыгаянова Фирсинә Өлфәт кызы, , I квалификацион категорияле укытучы<br>Петрова Гөләндәм Кәшиф кызы, I квалификацион категорияле укытучы |

Педагогик киңәшмә утырышында кабул ителде.

Беркетмә №1, " 29" нчы август. 2019 ел.

**1-4 сыйныфлар өчен туган тел (татар теле) фәненнән көтелгән предметнәтиҗәләре.**

1. Россиядә тел һәм мәдәният киңлегенең бердәмлеге һәм күптөрлелеге, телнең милли үзаң формалаштыру нигезе булуы турында беренчел күзаллаубулдыру.
2. Укучыларның телне милли мәдәният күренеше һәм аралашуның төп чарасы дип, татар телен милләтара аралашу теле итептанулары.
3. Кешенең гомуми культура күрсәткече, гражданлык позициясе булган телдән һәм язма дөрес сөйләмгә карата уңай карашформалаштыру.
4. Татар әдәби теле нормалары (орфоэпик, лексик, грамматик, орфографик, пунктуация), сөйләм әдәбе кагыйдәләре турында беренчел күзаллауга иябулу.
5. Аралашу вакытында куелган максат, бурыч һәм чаралардан чыгып, өйрәнгән материалны куллана белү; катлаулы булмаган монологик сөйләм һәм язма текстлар төзегәндә, коммуникатив бурычларны уңышлы үтәү өчен, туры килгән тел чараларын сайлый белү күнекмәләрен формалаштыру.
6. Хатасыз язуны культура дәрәҗәсенең бер күрсәткече итеп тану; үзе төзегән һәм тәкъдим ителгән текстларны язганда, орфография һәм тыныш билгеләре кагыйдәләрен дөрес кулланабелү.
7. Танып белү, гамәли һәм коммуникатив биремнәрне чишү өчен тел берәмлекләре һәм уку гамәлләренә иябулу;
8. Татар теленең системасы һәм төзелеше: фонетика, графика, лексикология, сүз төзелеше һәм сүз ясалышы, морфология һәм синтаксис; төп тел белеме берәмлекләре һәм аларның үзлекләре, сөйләмдә куллану үзенчәлекләре турында беренчел фәнни карашбулдыру.

## 2. 1-4 нче сыйныфлар өчен эш программасының эчтәлеге.

**1 нчесыйныф**

Беренче сыйныфта укучыларны грамотага өйрәтү ике чорга бүленә: грамотага әзерлек чоры, әлифба чоры ( төп чор). Грамотага өйрәтү үзара тыгыз бәйләнгән укый һәм яза белергә өйрәтүнең башлангыч процессыннан гыйбәрәт аналитик – синтетик аваз – хәреф методы белән тормышка ашырыла; авазлар һәм хәрефләр, иҗекләр һәм сүзләр, җөмләләр һәм бәйләнешле сөйләм өстендә эшләү күнегүләре аша ныгытыла. Аваз, хәреф — тану берәмлеге, иҗек — уку берәмлеге, сүз — аңлау берәмлеге, җөмлә — мәгълүмат-хәбәрлек берәмлеге (Кош оча. Балык йөзә.) икәнен гамәли аңлап, «чын уку һәм чын язу»ның җөмлә укудан һәм җөмлә язудан башланганын белеп эшләүләренәирешелә.

**Грамотага әзерлек чоры**

Язу гигиенасы кагыйдәләре белән таныштыру, кагыйдәләрне даими үтәү гадәте тәрбияләү. Кешеләрнең әйтеп һәм язып сөйләшүләрен гомуми күзаллау. Матур итеп сөйләшә, укый һәм яза белү кирәклеген аңлау. График схемалар ярдәмендә сөйләмне — җөмләләргә, җөмләне сүзләргә аеру, сүзләрне иҗек һәм авазларга таркату. Дәфтәр битендә ориентлашу. Язу сызыгы, язуның башлангыч ноктасы. Структур берәмлек буларак кулланылган сызык элементлары.Алгоритм буенча сызык элементларынязу.

**Әлифба чоры, яки төп чор**

Барлык баш һәм юл хәрефләренең язылышы һәм аларның тоташтыруның төп сызыклары белән таныштыру һәм каллиграфик дөрес язарга өйрәтү. Язуда өч төрле (аскы,урта,өске) тоташтыру алымы. Авазларны сүздә тиешле язма хәрефләр белән күрсәтү. Сүздәге хәрефләрне, аларны тоташтырган сызыкларын өзмичә ритмик язуны булдыру , дәфтәр юлларына хәрефләрне һәм сүзләрне, тигез ара калдырып, тигез, дөрес урнаштыру. Башта укытучы белән иҗек –аваз анализы ясаганнан соң, тора бара мөстәкыйль рәвештә сүзләр, җөмләләр язу. Башта язмача, аннары басмача үрнәкләрдән сүзләр, җөмләләр күчереп язу. Үрнәк текст белән чагыштырып карау һәм сүзләрне иҗекләп орфографик уку ярдәмендә дәфтәргә язылганнарның дөреслеген тикшерү. Әйтелеше белән язылышы арасында аерма булмаган сүзләрне, шундый өч-дүрт сүздән торган җөмләләрне диктант итеп язу.
**Татар теле дәресләре** әлифба курсы тәмамланганнан соң атнага 3 дәрес хисабыннанукытыла.

**Авазлар һәм хәрефләр**

Аваз һәм хәрефне аеру. Иҗекләрне һәм сүзләрне дөрес уку һәм язу. Сүзләрне иҗекләргә бүлү, аларны юлдан юлга күчерү. Сүзләр арасында буш урын калдыру, юлдан-юлга күчерү билгесе кую, кызыл юл кебек график чараларны куллану. Алфавиттагы хәрефләрнең исемен дөрес әйтү, аларның урнашу тәртибен белү. Сузык һәм тартык авазлар. Калын һәм нечкә сузыклар , аларны белдерә торган хәрефләрнең дөрес язылышы. Авазларның калынлыкта-нечкәлектә ярашуы. Яңгырау һәм саңгырау тартыклар, аларны белдерә торган хәрефләрнең дөрес язылышы. Парлы һәм парсыз яңгырау һәм саңгыраутартыклар.

**Синтаксис**

Җөмлә, сүзтезмә һәм сүзләрне аеру, аларның охшаш һәм аермалы якларын аңлау. Әйтү максаты ягыннан хикәя, сорау, тойгылы һәм боеру җөмләләр, аларны дөрес интонация белән уку. Җөмлә ахырында нокта, сорау һәм өндәү билгеләре кую.

**Морфология**

Сүз төркемнәре турында төшенчә бирү. Предметны белдерүче сүзләр. Уртаклык һәм ялгызлык исемнәр, аларның язылышы . *Кем? Нәрсә?* сорауларына җавап биргән исемнәрне аеру. Исемнәр янында кулланыла торган ярдәмче сүзләр- бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр. Эш- хәрәкәтне белдерүче сүзләр. Билгене белдерүчесүзләр.

**Бәйләнешлесөйләм**

Иҗекләрдән сүзләр, сүзләрдән сүзтезмәләр һәм җөмләләр төзү. Өч-дүрт җөмләдән торган хикәя төзеп язу. Рәсем буенча кечкенә хикәя төзү. Шигырь, табышмак, мәкальләрне ятлап хәтер диктанты язу.

**2 нчесыйныф**

## Фонетика һәм орфоэпия

Авазлар һәм хәрефләр. Сузык һәм тартык авазлар. Калын һәм нечкә сузыклар. Авазларның калынлыкта-нечкәлектә ярашуы. Язуда сузык авазларны белдерә торган хәрефләр. Аваз һәм хәрефләрне аеру. Сузык авазлар.

Иҗек. Сүзләрне иҗекләргә бүлү, юлдан-юлга күчерү кагыйдәләре.

Яңгырау һәм саңгырау, парлы һәм парсыз тартыклар. Язуда тартык авазларны белдерә торган хәрефләр. Татар теленә генә хас булган [w], [гъ], [къ], [х], [ч]; [ж], [н], [h] авазлары.

*Е, ю, я* хәрефләре кергән сүзләрне дөрес язу. Саңгырау тартыкларның яңгыраулашуы. Бертөрле ике тартык аваз хәрефләренең янәшә килүе.

*ъ* һәм *ь* хәрефләре кергән сүзләрне дөрес язу һәм уку.

## Графика

Татар алфавиты: хәрефләрнең тәртибен һәм исемен яттан белү. Сүзлекләр белән эшләгәндә, алфавиттан файдалана белү.

## Сүз

Сүз тамыры. Тамырдаш сүзләр. Кушымчалар. Сүз ясалу үзенчәлекләре.

Предметны белдергән сүзләр. Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр. Кеше исемнәрен, фамилияләрен, шәһәр, авыл, елга исемнәрен, хайван кушаматларын баш хәреф белән язу.

Эш-хәрәкәтне белдергән сүзләр. Аларның мәгънәсе һәм җөмләдә куллану үзенчәлекләре.

Предметның билгесен белдергән сүзләр, аларны җөмләдә куллану. Татар телендә исем һәм сыйфатның синтаксик бәйләнеш үзенчәлеге.

Сүз, сүзтезмәһәмҗөмлә. Сүзтезмә һәм җөмләләр төзү. Җыйнак һәм җәенке җөмлә. Җөмләнең баш кисәкләре. Җөмләдә сүз тәртибе. Әйтү максаты ягыннан җөмләнең төрләре, аларның дөресәйтелеше.

## Бәйләнешле сөйләм

Текстта җөмләләрнең урнашу тәртибе (үзара бәйләнеше). Текстның темасын билгеләү, төп фикерен табу. Текстны кисәкләргә бүлү һәм исем кую.

Рәсемнәр буенча, терәк сүзләр кулланып, текст төзү. Тәкъдим ителгән бирем буенча текстның эчтәлеген сөйләү.

Шигырь, мәкаль, әйтем һәм табышмаклар ятлау. Татар сөйләм әдәбенә хас булган сүзләрне дөрес куллану.

## 3 нчесыйныф

## Лексика. Сүз.

Сүз һәм аның лексик мәгънәсе.Бер мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләр, аларның аермасы.Сүзнең туры һәм күчерелмә мәгънәләре,аларны сөйләмдә куллану. Татар телендә алынма сүзләр.Синонимнар һәм антонимнар, омонимнар: аларны сөйләмдә куллану. Татар теленең сүзлек байлыгы.Татар телендә сүзлекләр: татар теленең аңлатмалы сүзлеге, синонимнар, антонимнар, омонимнар сүзлекләре һәм аларны көндәлек тормышта , уку эшчәнлегендә куллану.

## Сүз төзелеше һәм сүз ясалышы

Сүзнең мәгънәле кисәкләрен билгеләү: тамыр һәм кушымча. Сүз ясагыч кушымчалар турында төшенчә. Сүзне төзелеше буенча тикшерү. Тамырдаш сүзләр турында төшенчә. Аларның синонимнардан һәм омонимнардан аермасы. Тамырдаш сүзләр һәм бер үк сүзнең төрле формалары.

Сүзләрнең дөрес язылышын тикшерү ысуллары: сүзнең формасын үзгәртү, тамырдаш сүзләр сайлау, орфографик сүзлек куллану.

## Морфология

Сүз төркемнәре турында төшенчә.

**Исем.** Мәгънәсе һәм кулланылышы. Берлек һәм күплек саннары. Күплек сан кушымчаларының дөрес язылышы. Татар телендә килешләр һәм аларның сораулары. Исемнәрнең килеш белән төрләнеше. Исемнәргә морфологик анализ ясау күнегүләре.

**Фигыль.** Фигыльнең мәгънәсе һәм сөйләмдә кулланылышы. Фигыльнең барлык һәм юклык формалары. Фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. Хикәя фигыльнең хәзерге, үткән һәм киләчәк заманнары. -ар, -әр, -ыр, -ер, -р, -ачак, -әчәк, -ячак, -ячәк киләчәк заман хикәя фигыль кушымчаларының дөрес язылышын гамәли үзләштерү.

Фигыльләргә морфологик анализ.

**Сыйфат.** Мәгънәсе һәм сөйләмдә кулланылышы. Сыйфат дәрәҗәләре: гади(төп), чагыштыру, артыклык, кимлек. Чагыштыру дәрәҗәсендәге –рак, -рәк кушымчаларының һәм артыклык дәрәҗәсендәге кисәкчәләрнең дөрес язылышы.

**Алмашлык.** Алмашлык турында гомуми күзаллау.Зат алмашлыклары, мәгънәсе һәм сөйләмдә кулланылышы. Зат алмашлыкларының килеш белән төрләнеше.

**Кисәкчә**. *да, дә, та, тә* кисәкчәләрен *–да, -дә, -та, -тә* урын-вакыт килеше кушымчаларыннан аерып таный белү ысуллары. Кисәкчәләрнең дөресязылышы.

**Бәйлекләр**, аларның сөйләмдәге әһәмияте. Бәйлекләрне исемнәр һәм алмашлыклар белән төрле килешләрдә куллану.

## Синтаксис

**Җөмлә**. Әйтелү максатыннан чыгып, җөмләләрнең төрләре(хикәя, сорау, өндәү(боеру), тойгылы). Җөмлә ахырында тыныш билгеләре: нокта, сорау һәм өндәү билгеләре. Хикәя, сорау, өндәү(боеру), тойгылы җөмләләрнең интонацион үзенчәлекләре(гамәли үзләштерү).

Баш һәм иярчен кисәкләр турында төшенчә. Ия һәм хәбәр. Җөмләдә сүзләр бәйләнешен билгеләү.

Җөмләдә сүз тәртибе. Җыйнак һәм җәенке җөмләләр турында төшенчә.

**Сүзтезмә**. Сүз, сүзтезмә, җөмләнең охшаш һәм аермалы яклары. Сүзтезмәдәге ияртүче һәм иярүче сүзләрне таный белү.

## Бәйләнешлесөйләм

Текст. Текстның темасын, төп фикерен билгеләү, абзацларга бүлү. Тасвирлаучы һәм хикәяләүче текстларның төп үзенчәлекләре.

Сөйләм этикасы белән таныштыру.

# 4 нче сыйныф

## Сүз . Телнең сүзлек байлыгы .Сүзнең лексик мәгънәсе.

Сүз һәм аның мәгънәсе, бер генә мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләр, тотрыклы сүзтезмәләр, алынма сүзләр, синоним,антоним, омонимнар.Сүзне туры һәм күчерелмә мәгънәдә куллану. Искергән һәм яңа сүзләр. Бу белемнәрне гамәли сынапкарау.

Татарча-русча, русча- татарча сүзлекләр, орфографик сүзлек, аңлатмалы сүзлек, фразеологик әйтелмәләр сүзлеге .

## Сүз төзелеше

4 нче сыйныфта “Сүз төзелеше” темасы тагын да тирәнәйтелә: ясалма, кушма,парлы, тезмә сүзләрнең, ясалышы һәм дөрес язылышы, рус теленнән татар теленә кергән алынма кушма сүзләрнең үзенчәлекләре; сүз төзелешенә анализ ясау ,кушма сүзләрдә ь һәм ъ хәрефләренең язылыш кагыйдәләре, сингармонизм законына буйсынмаган сүзләргә сүз ясагыч кушымчаларның ялгану тәртибе. Сүз төзелешенәанализ.

**Сүз төркемнәре. Исем**

Мәгънәсе, сораулары, формалары, ясалышы, җөмләдәге урыны турында кабатлау. Исемнәрнең хәбәр булып килүләренә күзәтүләр. Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр. Берлек һәм күплек сандагы исемнәр. Исемнәрнең килеш һәм тартым белән төрләнеше. Калын һәм нечкә төрләнеш. Сингармонизм законына буйсынмаган сүзләргә кушымча ялгау. Килеш кушымчаларының дөресязылышы.

Баш килеш.Буформадаисемнәрнең җөмләдә ия, хәбәр, иярченкисәкбулаалулары. Төшемкилешененңмәгънәсе, җөмләдәгефункциясе.
Күплек сандагы исемнәрнең килешләр белән төрләнеше. Төрле килешләрдә исемнәрнең бәйлекләр белән кулланылуы.

**Фигыль**

Фигыль - катлаулы сүз төркеме. 4 нче сыйныфта 1-3 нче сыйныфта үткән материал искә төшерелә һәм хикәя фигыльнең билгеле үткән заман, нәтиҗәле үткән заман формалары; киләчәк заман формалары: билгесез киләчәк заман, билгеле киләчәк заман турында яңа мәгълүмат өстәлә. Фигыльнең барлык һәм юклыкформалары.

Боерык фигыль. Боерык фигыльнең мәгнәсе , зат-сан белән төрләнеше. Боерык фигыльне куллану, дөрес язу.

Фигыльнең җөмләдә хәбәр булып килүе, антоним Һәм синоним фигыльләр турында мәгълүмат бирү.

**Сыйфат**

Сыйфат дәрәҗәләре. Дәрәҗә формаларының ясалышы, дөрес язылышы һәм кулланылышы. Сыйфатның җөмләдәге роле (иярчен кисәкләр һәм хәбәр булып килүе).Сыйфатларның туры һәм күчерелмә мәгнәдә кулланылуы.Антоним сыйфатлар, синонимсыйфатлар.

**Алмашлык**

Алмашлык – мөстәкыйль сүз төркеме. Ул сөйләмдә башка сүз төркемнәрен (исем, сыйфат, сан һәм рәвешне) алыштырып килә. Алмашлык предметны яки билгене генә белдерми , ул бары тик үзе алыштырып килә торган сүз төркеменең грамматик билгеләренә ия була. Алмашлыкларның җөмләдәге роле. Зат алмашлыкларының килеш белән төрләнеше, дөрес язылышы кабатлана һәм сорау алмашлыклары турында яңа мәгълүмат бирелә. Килеш сораулары сорау алмашлыкларына керәләр. . Алмашлыкларның сөйләмдәкулланылышы.

**Сан**

Сан предметның исәбен, микъдарын белдерә торган сүз төркеме. Сан исем белән кулланылганда төрләнми. Җөмләдәге роле. Кайбер сан төркемчәләре :микъдар саннары, тәртип саннары.

**Рәвеш**

Рәвеш - мөстәкыйль сүз төркеме, лексик-грамматик яктан эш-хәлнең билгесен, ничек үтәлүен белдерә.Рәвешләрнең җөмләдәге роле.

Морфологик яктан - төрләнми. Ул ничек? кайчан? кая? кайда? никадәр? күпме ? кебек сорауларга җавап бирәләр. Эш яки хәлнең билгесен, ничек үтәлүен белдерә торган сүз төркеме.

Сөйләмдә актив кулланыла торган рәвешләр, аларның дөресязылышы.

**Кисәкчәләр**

Кисәкчәләр турында беренче мәгълүмат 3 нче сыйныфта бирелә. Кисәкчәләр (*да, дә, та, тә, гына, генә, кына, кенә, ук, үк, ич, бит*). Аларның дөрес язылышы.

Кисәкчәләр сүз яки җөмләгә төрле төсмер өстәү өчен кулланылуы ачыклана.Кисәкчәләр аерым торганда мәгънә белдерми. Бик күп кисәкчә күп мәгънәле була,һәм аларның мәгънә төсмерләре нинди сүзгә иярүләренә, кайсы урында килүләренә, җөмлә төзелешенә, аның интонациясенә карап үзгәрә.

**Бәйлекләр**

1-3 нче сыйныфларда өйрәнгәннәрне кабатлау. Бәйлек- ярдәмче сүз, шуңа күрә, төшенчәдә төп урынны бәйлекнең функциясе, үтәгән хезмәте алып тора: бәйлекләр сүзләрне бәйлиләр.Төрле килешләрдә исемнәрнең һәм зат алмашлыкларының бәйлекләр белән килүенә күзәтүләр. Бәйлек төшенчәсе грамматик категория итепаңлатыла.

**Сүзтезмә**

4 нче сыйныфта сүзтезмәләргә шактый эзлекле мәгълүмат бирү күздә тотыла : сүзтезмә һәм тезмә сүзләр арасындагы аерманы аңлату, сүзтезмәләрнең барлыкка килү юлларын нигыту, сүзтезмәдәге иярүче һәм ияртүче сүз турында белемнәрне тирәнәйтү.

**Җөмлә**

Җөмләнең баш кисәкләре. Баш һәм иярчен кисәкләрнең аермасы. Җөмләдә сүзләр бәйләнеше. Ия белән хәбәр билгеләмәсе . Җыйнак һәм җәенке җөмләләр .Җөмләнең иярчен кисәкләре. Аергыч. Аергычка билгеләмә бирү Һәм аның сыйфат белән белдерелүе.

**Җөмләнең тиңдәшкисәкләре**

Җөмләнең тиңдәш кисәкләрен һәм тиңдәш кисәкләрнең үзара санау интонациясен, теркәгечләр ярдәмендә бәйләнешен төшендерү, тиңдәш кисәкләр янында тыныш билгеләренең куелышын аңлату. Тиңдәш ияле һәм тиңдәш хәбәрле җөмләләр.Тиңдәш кисәкләр арасында ***һәм, я, да-дә, та-тә, ә, ләкин*** теркәгечләре, тиңдәш кисәкләр янында тынышбилгеләре.

Эндәш сүзләр турында төшенчә бирү. Эндәш сүзләр һәм алар янында тыныш билгеләрен куярга өйрәтү.

Гади һәм кушма җөмләләр турында төшенчә бирү. Составында 2-3 гади җөмлә булган кушма җөмләләр**.** Тезмә кушма җөмләләрдә ***һәм, ә, ләкин, әмма*** теркәгечләре, алар янында тынышбилгеләре.

**Бәйләнешле сөйләм**

Сөйләм, аның тормыштагы роле. Билгеле бер темага караган төрле (сурәтләү, хикәяләү характерындагы) сөйләм текстлары кулланып, телдән монологик сөйләмне гамәли яктан үзләштерү.

Текст. Текст билгеләре. Тексттагы җөмләләрнең мәгънәви бердәмлеге. Текстка исем бирү.

Тексттагы җөмләләрнең эзлеклелеге. Текст кисәкләренең (өлешләренең) эзлеклелеге, кызыл юл турында төшенчә.

Текстка исем бирү, җөмлә һәм текст кисәкләрен билгеләү, җөмлә һәм текст кисәкләре эзлеклелеген төзәтү.

Текстның планын төзү. Бирелгән план буенча үз текстыңны төзү.

Сурәтләү һәм хикәяләү характерындагы текстлар, аларның үзенчәлекләре.

Котлау тексты һәм хат язу. Язма сөйләмнең төгәллеген, дөреслеген һәм сәнгатьлелеген саклап, үз текстыңны төзү һәм бирелгән текстларны тикшереп төзәтү, текстта синонимнар, антонимнар куллану.

Изложение һәм сочинениенең төп төрләре белән танышу (билгеләмәләрен ятламыйча): бирелгән текстны тулысынча файдаланып яки аерым урыннарын (сүзләрен) сайлап алып языла торган изложение, сочинение элементлары булган изложение, хикәяләү-сурәтләү рәвешендәге сочинение һ.б.

**3. Һәр теманы үзләштерү өчен бирелгән сәгать санын күрсәтеп, тематик планлаштыру.**

| Белем бирүнең эчтәлеге | Сәгать-ләр саны | Укыту эшчәнлегенең төп төрләре |
|---|---|---|
| **1 класс** | | |
| **Грамотага әзерлек чоры** | **6** | Язу гигиенасы кагыйдәләре белән таныштыру, кагыйдәләрне даими үтәү гадәте тәрбияләү. Кешеләрнең әйтеп һәм язып сөйләшүләрен гомуми күзаллау. Матур итеп сөйләшә, укый һәм яза белү кирәклеген аңлау.<br>График схемалар ярдәмендә сөйләмне — җөмләләргә, җөмләне сүзләргә аеру, сүзләрне иҗек һәм аваз-ларга таркату. |
| **Әлифба чоры** | **52** | Барлык баш һәм юл хәрефләренең язылышы һәм аларның тоташтыруның төп сызыклары белән таныштыру һәм каллиграфик дөрес язарга өйрәнү. Авазларны сүздә тиешле язма хәрефләр белән күрсәтү. Сүздәге хәрефләрне, аларны тоташтырган сызыкларын өзмичә ритмик язуны(ас-ос) булдыру, дәфтәр юлларына хәрефләрне һәм сүзләрне, тигез ара калдырып, тигез, дөрес урнаштыралар. Башта укытучы белән иҗек–аваз анализы ясаганнан соң, тора бара мөстәкыйль рәвештә сүзләр, җөмләләрязу.<br>Башта язмача, аннары басмача үрнәкләрдән сүзләр, җөмләләр күчереп язу. Үрнәк текст белән чагыштырып карау һәм сүзләрне иҗекләп орфографик уку ярдәмендә дәфтәргә язылганнарның дөреслеген тикшерү. Әйтелеше белән язылышы арасында аерма булмаган сүзләрне, шундый өч-дүрт сүздән торган җөмләләрне әйтепязу. |
| **Әлифбадан соңгы чор** | **1** | Алфавитны дөрес язу,уку.Аерым сүзләр белән җөмләләр төзеп язу. Текстны дөрес итеп күчереп язу. |
| **Авазлар һәм хәрефләр** | **25** | Сузык һәм тартык авазларны аера белү. Калын һәм нечкә сузыклар, аларны белдерә торган хәрефләрнең дөрес язылышын камилләштерү. Авазларның калынлыкта-нечкәлектә ярашуын истә калдыру. Язуда **ъ** һәм **ь** хәрефләрен **дөрес** куллану. **Е – ё**, **ю**, **я** хәрефләре булган сүзләрдә аваз һәм хәреф бәйләнешен билгеләү. Иҗекләрне һәм сүзләрне дөрес уку һәм язуны ныгыту. Сүзләрне иҗекләргә бүлү,аларны юлдан юлга күчерүне камилләштерү. Сүзне тиешле басым белән укырга өйрәнү. Дөресязу |

| | | |
|---|---|---|
| | | кагыйдәләре һәм аларның кулланылышы белән танышу: **о**, **ө** хәрефләренең татар сүзләренең беренче иҗегендә генә язылуын истә калдыру. |
| **Синтаксис** | **2** | Җөмлә чикләрен таба белү. Җөмлә башындагы сүзне баш хәреф белән язу, җөмләахырында нокта, сорау һәм өндәү билгеләрен дөрес куюныкамилләштерү. |
| **Морфология** | **5** | Предметны белдергән сүзләр белән танышу. Аларның мәгънәләрен аңлату, сорауларынәйтү;<br>Уртаклык һәм ялгызлык исемнәр һәм аларның язылышын камилләштерү. Исемнәр янында кулланыла торган ярдәмче сүзләр- бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр белəнтанышу.<br>Предметның билгесен белдергән сүзләр, аның мәгънәсе һәм сөйләмдә кулланылышы белән танышу.<br>Эш-хәрәкәтне белдергән сүзләр белəнтанышу. |
| **Орфография** | **8** | Сүздә орфограмманы күрү,аерып алу, дөрес язу, шул орфограммага сүзләр табу. Җөмләнең беренче сүзендә,кеше исемнәрендә, кеше фамилияләрендә,хайван кушаматларында,географик атамаларда баш хәреф язу. |
| **Бәйләнешле сөйләм үстерү** | **5** | Кечкенә текстларны дөрес итеп ( иҗек һәм хәрефләрне төшереп калдырмыйча, урыннарын алыштырмыйча ), сүзләп күчереп язу. Әйтелеше белән язылышы туры килгән сүзләрдәнтөзелгән җөмләләрне ишетеп язу. Шигырь, мәкаль, әйтем һәм табышмакларны хәтер диктанты итеп язарга өйрәнү. Тыңлаганның яки укыганның эчтәлеген изложение итеп язарга өйрәнү. Үзлекләреннәнзур булмагантекстлар (сочинение) иҗатитепязу. |
| | **2 нчесыйныф** | |
| **Фонетика һәм орфоэпия** | **35** | Аваз белән хәреф арасындагы аерманы аңлау; туган тел авазларына характеристика бирү: калын /нечкә сузыклар; парлы/парсыз, яңгырау/ саңгырау тартыклар;<br>Сүздәге басымлы һәм басымсыз авазларны табу. Сузык һәм тартык авазларга характеристика бирү.<br>Татар теленә генә хас булган авазларны дөрес әйтү. Сүзне иҗекләргә аеру, иҗекләр санын билгеләү.<br>Күчереп язганда һәм әйтеп яздырганда өйрәнелгән кагыйдәләрне куллану. |
| **Графика** | **4** | Аваз һәм хәрефләрне аеру: аваз билгесе буларак хәреф. Алфавиттагы хәрефләр тәртибен белү, сүзләрне алфавит тәртибендә урнаштыру өчен һәм кирәкле мәгълүматны тапканда алфавиттан файдалану. |
| **Сүз** | **45** | Тексттан тамырдаш сүзләрне табу. Тамырдаш сүзләрне аеру һәм тамырын билгеләү. Тамырдаш сүзләрне һәм сүз формаларны аеру. Сүзнең төп өлешен табу. Кем? Нәрсә? сорауларына җавап бирә торган исемнәрне белү. Уртаклык һәм ялгызлык исемнәрен таныпбелү.<br>Нинди? Кайсы? сорауларына җавап бирә торган сыйфатларны танып белү. Сөйләмдә сыйфатларны дөрес куллана белү. Нишли? Нишлиләр? Нишләр? Нишләрләр? сорауларына җавап бирә торган фигыльләрне тану һәм сөйләмдә дөрес кулланабелү. |
| **Җөмлә** | **7** | Җөмләне сүзләр төркеменнән аеру, аның чикләрен билгеләү. Сүзләрдән җөмләләр төзү. Җөмләнең баш |

| | | |
|---|---|---|
| | | һәм иярчен кисәкләрен табу. Җыйнак һәм җәенке җөмләләр төзү. Җөмләдәге сүзләр бәйләнешен көйләү. Бирелгән сүзләрдән җөмлә төзү. Җөмләдәге барлык сүзтезмәләрне табу. Җыйнак һәм җәенке җөмләләрне аеру. Әйтү максаты һәм эмоциональ бизәге буенча җөмләнең өч төренбилгеләү. |
| **Бәйләнешле сөйләм** | **11** | Текстның темасын һәм төп фикерен билгеләү. Текстка исем бирү, текст белән аның исемен туры китерү. Тәкъдим ителгән башлам өлеше һәм терәк сүзләр ярдәмендә рәсем буенча хикәя төзү.<br>Текстның планын төзү һәм аны телдән сөйләгәндә һәм язмача хикәяләгәндә куллану. Текстта мәгънәле кисәкләрне билгеләү. Билгеләнгән темага, төрле сөйләм типларын кулланып, хикәя төзү: тасвирлау, хикәяләү, фикерләү; сөйләм этикетының, сөйләм әдәбенең (укучылар һәм өлкәннәр белән аралашканда) төп кагыйдәләрен ныгыту; өйрәнелгән сүзлек байлыгы нигезендә әдәби сөйләмнең төп кагыйдәләрен үзләштерү. |
| **3 нчесыйныф** | | |
| **1-2 сыйныфларда өйрәнгәннәрне кабатлау** | **13** | Яңгырау, саңгырау тартыкларны һәм сузык авазларны танып белү; өйрәнгән орфограммаларны табу һәм сүзнең дөрес язылышын аңлату, орфографик сүзлекләр куллану.<br>Сүзләрне иҗекләргә бүлү һәм аларның санын билгеләү. Иҗекләргә бүлеп, сүзләрне юлдан-юлга күчерү. Сүзләрне юлдан-юлга күчергәндә ясалган хаталарны төзәтә белү.<br>Орфографик һәм орфоэпик сүзлекләр белән эшләгәндә, алфавиттан файдалану. |
| **Лексика. Сүз** | **12** | Бер мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләрне, сүзнең туры һәм күчерелмә мәгънәләрен танып белү; текстларда, үз сөйләмендә күчерелмә мәгънәле сүзләрне куллана белү.<br>Тамырдаш сүзләрне синонимнардан һәм омонимнардан аера белү. Тексттан синоним һәм антонимнарны билгеләү. |
| **Сүз төзелеше һәм сүз ясалышы** | **12** | Сүзләрне тамыр һәм кушымчаларга аеру.<br>Тамырдаш сүзләрнебилгели алу. Сүз ясалыш ысулларын танып белү. |
| **Морфология<br>Исем** | **17** | Исем, сыйфат, алмашлык, фигыль сүз төркемнәрен танып белү.<br>Җанлы һәм җансыз, ялгызлык һәм уртаклык исемнәрне тану; исемнәрне килеш, сан белән төрләндерү, килешләрнең исемнәрен дөрес әйтү. |
| **Фигыль** | **24** | Фигыльләрне заман, зат-сан белән төрләндерү. Хәзерге, үткән, киләчәк заман хикәя фигыльләрне зат-сан белән төрләндерү. |
| **Сыйфат** | **9** | Сыйфатларны таный алу, сыйфат дәрәҗәләрен сөйләмдә дөрес куллану. |
| **Алмашлык** | **5** | Зат алмашлыкларын килеш белән төрләндерү. Кушымчаларына карап, зат алмашлыкларының кайсы килешкә каравын билгеләү. |
| **Кисәкчә** | **5** | да, дә, та, тә кисәкчәләрен –да, -дә, -та, -тә урын-вакыт килеше кушымчаларыннан аера белү. |

| | | |
|---|---|---|
| **Бәйлекләр** | **2** | Бәйлекләрне исемнәр, алмашлыклар белән төрле килешләрдә куллану. |
| **Синтаксис. Җөмлә** | **13** | Җөмләнең баш(ия, хәбәр), иярчен кисәкләрен билгеләү. Җөмләнең баш кисәкләрен табу. |
| **Сүзтезмә** | **3** | Җөмлә, сүзтезмә, сүзне, сүзтезмәдәге ияртүче, иярүче сүзләрне аера белү. |
| **Сөйләм үстерү** | **11** | Яшьтәшләре һәм өлкәннәр белән аралашканда сөйләм этикеты нормаларына ия булу. “Текст”, “абзац”,“текст планы”; текстның башы һәм ахыры төшенчәләрен белү. Бирелгән текстларга план төзү, абзацларны билгеләү, тексттагы җөмләләрнең бәйләнешен билгеләү. |
| **Ел буена үткәннәрне кабатлау** | **10** | Арадаш аттестация эше. “Сүзнең төп (лексик) мәгънәсе” темасы. Контроль диктант. Хаталар өстендә эш. Сүз төзелеше. Сүз ясалышы. Исем. Исемнәрнең килеш белән төрләнүе. Фигыль. Фигыльнең заман белән төрләнеше. Сыйфат. Кисәкчәләр. Бәйлекләр. Бәйләнешлесөйләм |
| **4 нчесыйныф** | | |
| **1-3 нче сыйныфларда үткәннәрне кабатлау** | **8** | Фонетика,морфология һәм синтаксистан үткәннәрне кабатлау һәм тирәнәйтүне күздә тоту. Фонетикадан аваз һәм хәреф, алар арасындагы аерма, тартык һәм сузык авазлар, аерым авазларның дөрес әйтелешен һәм язылышын өйрәнү. Морфология буенча сүз төзелеше һәм арым сүз төркемнәре искә төшерү. Синтаксистан җөмлә һәм аның төрләре искәтөшерү. |
| **Сүз. Телнең сүзлек байлыгы. Сүзнең лексикмәгънәсе.** | **8** | Сүз һәм аның мәгънәсен, бер генә мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләрне, алынма сүзләрне, синоним,антоним, омонимнарны искә төшерү. Бу белемнәрне гамәли сынап карарга өйрәнү. Төрле сүзлекләр белән эшләү күнекмәләренныгыту. |
| **Сүз төзелеше** | **11** | Ясалма, кушма, парлы, тезмә сүзләрнең ясалышы һәм язылышы, рус теленнән татар теленә кергән алынма кушма сүзләрнең үзенчәлекләре белән танышу. Сүз төзелешенә анализ ясарга өйрәнү. |
| **Сүз төркемнәре. Исем** | **8** | Исемнең мәгънәсе, сораулары, формалары, ясалышы, җөмләдәге урыны турында кабатлау.<br>Исемнәрнең хәбәр булып килүләренкүзәтүләр.<br>Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр, берлек һәм күплек сандагы исемнәр турында белемнәрен тирәнәйтү.<br>Исемнәрнең килеш һәм тартым белән төрләнешен тирәнтен өйрәнү.<br>Калын һәм нечкә төрләнеш белән танышу. Сингармонизм законына буйсынмаган сүзләргә кушымча ялгарга өйрәнү.<br>Килеш кушымчаларының дөрес язылышы белән танышу.<br>Баш килеш формасында исемнәрнең җөмләдә ия, хәбәр, иярчен кисәк була алуларына төшенү. Төшем килешенең мәгънәсе, җөмләдәге функциясе белән танышу. |
| **Фигыль** | **13** | Хикәя фигыльнең билгеле үткән заман, нәтиҗәле үткән заман формалары, киләчәк заман формалары: билгесез киләчәк заман, билгеле киләчәк заман турында яңа мәгълүмат алу. |

| | | |
|---|---|---|
| | | Боерык фигыльнең мәгнәсе , зат-сан белән төрләнеше, боерык фигыльне куллану, дөрес язу турында белем алу.<br>Фигыльнең җөмләдә хәбәр булып килүе, антоним һәм синоним фигыльләр турында мәгълүмат алу.<br>Фигыльгә морфологик анализясау. |
| **Сыйфат** | **7** | Сыйфат, аның мәгънәсе һәм сөйләмдә куллану. Сыйфатның сорауларын ныгыту. Сыйфатның төс, тәм, форма, күләм, характер һ.б. билгеләрне белдерүе белән танышу. Сыйфат дәрәҗәләре белән танышу. Кайбер сыйфатларны гына дәрәҗәгә куепбула.<br>Җөмләдә сыйфат исемне ачыклап килә һәм күбесенчә аергыч була. Сыйфатның исемгә бәйләнеп килүе. Сыйфатның җөмләдәге функциясе( аергыч, хәбәр), синоним һәм антоним сыйфатларны өйрәнү. Сыйфатка морфологик анализясау. |
| **Алмашлык** | **6** | Алмашлык турында гомуми төшенчә бирү.Алмашлыкларның җөмләдәге ролен өйрәнү. Зат алмашлыклары, аларның мәгънәсе һәм сөйләмдә кулланылышы. I, II, III зат алмашлыклары, аларның берлек һәм күплек сан формалары, килеш белән төрләнешен өйрәнү. Зат алмашлыкларының килеш белән төрләнеше, дөрес язылышын кабатлау һәм сорау алмашлыклары турында яңа мәгълүмат алу. Килеш сорауларының сорау алмашлыкларына керүен белү. Сорау алмашлыкларына тагын ***нинди, кайсы, ничек, ник, нигә, ничәнче*** кебек сүзләр керүе беләнтанышу. |
| **Сан** | **6** | Предметның исәбен, микъдарын белдерә торган сүз төркеме белән танышу.<br>Санның исем белән кулланылганда төрләнмәвен төшенү.<br>Җөмләдә аергыч, хәбәр һәм исемнән башка кулланылганда, җөмләнең бүтән кисәкләре дә була алуынаңлау.<br>Санның билгеләмәсе(мәгънәсе, сораулары) белән танышу.<br>Санның исемне ачыклап килүе, сан белән ачыкланып килгән исемнең саналмыш булуы, кайбер сан төркемчәләре(микъдар саннары, тәртип саннары) турында беренче мәгълүмат алу. |
| **Рәвеш** | **5** | Рәвешнең ничек?, кайчан? Кая? Кайда? Никадәр? Күпме? кебек сорауларга җавап булып килүе, эш яки хәлнең билгесен, ничек үтәлүен белдерә торган сүз төркеме булуынаңлау.<br>Мөстәкыйль сүз төркеме, лексик-грамматик яктан эш-хәлнең билгесен, ничек үтәлүен белдерүен, морфологик яктан – төрләнмәвен,<br>кайбер рәвешләрнең артыклык яисә чагыштыру дәрәҗәсендә килә алуларын аңлау.<br>Синтаксик яктан- җөмләдә фигыльне,сыйфатныһәм рәвешне дә ачыклап килүен, төп синтаксик функциясе- хәл икәнлегенәтөшенү. |
| **Кисәкчәләр.Бәйлекләр.** | **4** | Кисәкчәләрнең сөйләмдәге роле-мәгънә, хис төсмерләрен, раслау, инкяр итүне белдерүе белән танышу.<br>Аларны сөйләмдә дөрескуллану. |

| | | |
|---|---|---|
| | | Биккүп кисәкчәләрне күп мәгънәле булаалуынһәм аларның мәгънә төсмерләре нинди сүзгә иярүләренә, кайсы урында килүләренә, җөмлә төзелешенә, аның интонациясенә карап үзгәрүен аңлау. Бәйлекләр сүзләрне бәйләгәндә, килешкә якын мәгънә белдерүен, үзләреннән алда килгән сүзнең билгеле бер килештә торуын, соравыбеләнтанышу. Шуңа карап бәйлекләрне өч төркемчәгә аерырыга (баш, юнәлеш һәм чыгыш килеше)өйрәнү. |
| **Сүзтезмә** | **2** | Сүзтезмә һәм тезмә сүзләр арасындагы аерманы аңлау, сүзтезмәләрнең барлыкка килүюлларын ачыклау, сүзтезмәдәге иярүче һәм ияртүче сүз турында белемнәрнетирәнәйтү. |
| **Җөмлә** | **10** | Ия белән хәбәр таба белүне, сорауларын куюны ныгыту.<br>Җыйнак һәм җәенке җөмләләр турында белемнәрне ныгыту. Җыйнак җөмләне тиешле сүзләр өстәп, җәенкеләндерә белү, җәенке җөмлә эченнән баш кисәкләрне аерып алу кебек күнегүләр эшләнелә**.**<br>Аергыч турында мәгълүмат алу.<br>Җөмләдән иярчен кисәкләрне (аергычны) таба белү.<br>Тиңдәш ияле, тиңдәш хәбәрле, тиңдәш аергычлы җөмләләр турында мәгълүмат алу.<br>Тиңдәш кисәкләр арасында теркәгечләр булганда тыныш билгеләрен куярга өйрәнәләр.<br>Эндәш сүзләр турында мәгълүмат алалар.<br>Составында 2-3 гади җөмлә булган тезмә кушма җөмләләрне тиңдәш кисәкле гади җөмләләрдән аера һәм тикшерергәөйрәнү.<br>Теркәгечләрне һәм тыныш билгеләрен куюны өйрәнү. |
| **Текст. Бәйләнешле сөйләм.** | **12** | Текстның темасын ,төп фикере, аның өлешләрен билгели белү осталыгын камилләштерәләр.<br>Текстларның төрләре (хикәяләү, тасвирлау, фикер йөртү). Текстларны бер- берсеннән аера һәм төзергә өйрәнәләр. Текстта сурәтләү чаралары. Текстларның эчтәлеген кыскартып һәм тулысынча сөйләү.<br>Котлау открыткасы, хат, СМС язарга өйрәнү.<br>Сөйләм этикасына караган күнегүләр. Аралашу ситуациясен – аралашу кем белән, кайда, нинди максат белән башкарылуын аңлау. Үз фикереңне әйтү һәм аны дәлилләү. Әңгәмә үткәрүнең төп күнекмәләрен үзләштерү (сүз башлау, әңгәмәгә кушылу, аны дәвам итү, игътибарны җәлеп итү һ.б.). Уку, конкрет аралашу шартларында тел әдәбе нормаларын үзләштерү (сәламләү, хушлашу, гафу үтенү, рәхмәтле булу, сорау белән мөрәҗәгать итү).<br>Монологик сөйләм төзү күнекмәләрен камилләштерү. |